**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 27 » 07 2021 № 235

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге
тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
административ регламентларын раслау турында»
2020 ел, 13 октябрь, №646 карарына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»2010 ел, 27 июль, 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 ел, 2 ноябрь, №880 карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон рәвештә социаль әһәмияткә ия дәүләт хезмәтләрен, дәүләт биреме (заказ) урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрен күрсәтүгә күчү буенча чаралар планын раслау турында» 2021 ел, 13 апрель, №242 карарына таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2018 ел, 26 ноябрь, №651 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2020 ел, 13 октябрь, №646 карарына (2021 ел, 12 гыйнвар, №3; 2021 ел, 1 июль, №208; 2021 ел,1 июль, №210 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

«Торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган (торак) бинага күчерү (күчерүдән баш тарту) турында хәбәрнамә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты» 7 нче кушымтасын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Күпфатирлы йортта бинаны үзгәртеп коруны һәм (яки) яңадан планлаштыруны килештерү (килештермәү) турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 11 нче кушымтасын әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 12 нче кушымтасын әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»13 нче кушымтасын әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 14 нче кушымтасын әлеге карарның 5 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 16 нче кушымтасын әлеге карарның 6 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Инженерлык челтәрләре һәм коммуникацияләр трассалары схемасын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»17 нче кушымтасын әлеге карарның 7 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Агач һәм куаклар кисүгә, ябалдашларын кыскартука яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 18 нче кушымтасын әлеге карарның 8 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Ана (гаилә) капиталы акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне башкаруны тикшерү актын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 19 нчы кушымтасын әлеге карарның 9 нчы кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Җир кишәрлегеннән шартлы рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 22 нче кушымтасын әлеге карарның 10 нчы кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Аксубай муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен һәм тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга рөхсәтләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 23 нче кушымтасын әлеге карарның 11 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрлары планлаштырыла торган төзелеш турындагы хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең

административ регламенты» 24 нче кушымтасын әлеге карарның 12 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

«Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрларын планлаштырыла торган төзү турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларга туры килү һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларын планлаштырыла торган төзелеше параметрларының билгеләнгән параметрларга туры килмәве һәм (яисә) объектны урнаштыруның рөхсәт ителмәве турында хәбәрнамәне юллау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты турында» 25 нче кушымтасын әлеге карарның 13 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

27 һәм 28 нче кушымтаны төшереп калдырырга;

- карарны түбәндәге эчтәлекле 1.27, 1.28, 1.30, 1.31 пунктчалар белән тулыландырырга:

«1.27. Капиталь төзелеш объектын сүтү планлаштырыла торган хәбәрнамә һәм капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлануы турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (27 нче кушымта);

1.28. Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен билгеле бер категориягә күчерү яки җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (28 нче кушымта);

1.30. Даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкны һәм даими пассажирлар йөртү маршруты карталарын рәсмиләштерү, даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкларны һәм даими пассажирлар йөртү маршруты карталарын яңадан рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (30 нчы кушымта);

1.31. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (31 нче кушымта)».

- әлеге карарның 14,15,16,17 нче кушымталары нигезендә карарны 27, 28, 30, 31 нче кушымталар белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo. tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең финанслар һәм мөлкәт белән идарә итү буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.Ю.Зайцев